КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 4 июль

г.Казань

№ 551

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән сатып алынган күчемле мөлкәтне эксплуатацияләүче оешмаларга тапшыру тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән сатып алынган күчемле мөлкәтне эксплуатацияләүче оешмаларга үз вакытында тапшыруны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән сатып алынган күчемле мөлкәтне эксплуатацияләүче оешмаларга тапшыру тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән сатып алынган күчемле мөлкәтне кабул иткәндә Тәртипнең нигезләмәләрен куллануны тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына, кабул итү-тапшыру актларына кул куйганнан соң һәм бу мөлкәтне балански алганнан соң, бу карарның 1 нче пункты белән расланган Тәртип нигезендә күчемле мөлкәтне тапшыру нәтиҗәсендә барлыкка килә торган чыгымнарны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауны гамәлгә ашырырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 4 июль, 551 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән сатып алынган
күчемле мөлкәтне эксплуатацияләүче оешмаларга тапшыру
тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Тәртип күчемле мөлкәтне (алга таба – Мөлкәт) муниципаль милеккә, шулай ук дәүләт учреждениеләренә оператив идарәгә, дәүләт унитар предприятиеләренә хуҗалык алып баруга яки башка оешмаларга түләүсез файдалануга тапшырганда «Татарстан Республикасының Баш инвестицион-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Баш инвестицион-төзелеш идарәсе), Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Министрлык), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары), Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре (алга таба – дәүләт учреждениеләре), Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре (алга таба – дәүләт унитар предприятиеләре) һәм башка оешмаларның (алга таба – катнашучылар) үзара хезмәттәшлеге тәртибен һәм гомуми кагыйдәләрен билгели.

1.2. Бу Тәртип Баш инвестицион-төзелеш идарәсенең товар кайтару, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү төп предметы булып торган дәүләт контрактлары, шартнамәләр буенча дәүләт заказчысы функцияләрен башкарганда сатып алынган Мөлкәтне тапшыру мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

1.3. Бу Тәртиптә катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге законнарны, шул исәптән «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, ФЗ-131 нче, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясенең закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2004 ел, 22 август, ФЗ-122 нче федераль законнарны исәпкә алып даими нигездә гамәлгә ашырыла.

1.4. Министрлыкның Мөлкәтне тапшыру турындагы боерыклары Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары арасында законнар белән билгеләнгән вәкаләтләрне чикләү принцибы нигезендә кабул ителә.

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән мөлкәт Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең муниципаль милкенә тапшырыла.

Татарстан Республикасы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәк булган мөлкәт дәүләт учреждениеләренә – оператив идарәгә, дәүләт унитар предприятиеләренә хуҗалык алып баруга тапшырыла.

Башка оешмалар (федераль дәүләт учреждениеләре, коммерциягә карамаган оешмалар һәм башкалар) эшчәнлеге өчен кирәк булган мөлкәт тиешле оешмаларның түләүсез файдалануына тапшырыла.

1.5. Министрлык Мөлкәт тапшыру турындагы тиешле боерыкларны кабул иткәндә, кабул итүче якларның ризалыгын раслаучы документлар булып товар йөкнамәләре (спецификацияләр), кабул итү комиссиясе тарафыннан объектларны кабул итү актлары, кабул итү-тапшыру актлары, кабул итүче якның вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имзаланган башка документлар тора.

Кабул итү комиссиясенең объектларны (мәсәлән, энергия ресурсларын исәпкә алу узеллары, универсаль спорт мәйданчыклары) кабул итү акты белән рәсмиләштерелеп, файдалануга кертелә торган Мөлкәт әлеге актка эксплуатацияләүче оешма (балансta тотучы) буларак кул куйган оешмаларга тапшырыла.

1.6. Бу Тәртипне тормышка ашырганда Катнашучыларның үзара хезмәттәшлеген оештыруны Баш инвестицион-төзелеш идарәсе тәэмин итә.

## 2. Төп максатлар һәм бурычлар

2.1. Бу Тәртип Мөлкәтне муниципаль милеккә, шулай ук дәүләт учреждениеләренә, дәүләт унитар предприятиеләренә яки башка оешмаларга үз вакытында тапшыруны тәэмин итү максатларында эшләнде.

2.2. Бу Тәртип кысаларында Катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге Мөлкәтне тапшыру максатларында Министрлыкка, җирле үзидарә органнарына, дәүләт учреждениеләренә, дәүләт унитар предприятиеләренә яки башка оешмаларга Баш инвестицион-төзелеш идарәсе тарафыннан кертелә торган документларны карап тикшерү вакытларын оптимизацияләүгә юнәлдерелә.

## 3. Үзара хезмәттәшлек итү тәртибе һәм рәвешләре

3.1. Баш инвестицион-төзелеш идарәсе, бу Тәртипнең 1.3 нче һәм 1.4 нче пунктларын исәпкә алып, түбәндәгеләрне җибәрә:

Мөлкәт исемлеге белән аны муниципаль милеккә кабул итүгә ризалык турында хат бирү хакындагы сорауны – Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына яисә товар йөкнамәләре (спецификацияләр) күчермәләрен, кабул итү комиссиясе тарафыннан объектларны кабул итү актларын һәм Мөлкәтне кабул итүче оешмаларның (эксплуатацияләүче оешма (балансta тотучы) вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имзаланган кабул итү-тапшыру турындагы башка актларны – Министрлыкка;

Мөлкәтне кабул итү-тапшыру актлары проектларын Мөлкәт исемлеге белән – дәүләт учреждениеләренә, дәүләт унитар предприятиеләренә (шул исәптән дәүләт учреждениеләренең, дәүләт унитар предприятиеләренең электрон адресына);

Мөлкәт исемлеге белән аны файдалануга алуга ризалык турында хат бирү хакындагы сорауны – башка оешмаларга.

3.2. Баш инвестицион-төзелеш идарәсенең Мөлкәтне кабул итүгә ризалык турында хат бирү хакындагы соравын карап тикшерү нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органнары һәм тиешле сорау җибәрелгән оешмалар аны алган көннән 10 эш көне эчендә Баш инвестицион-төзелеш идарәсенә Мөлкәтне муниципаль милеккә, оешмалар түләүсез файдалануга алуга ризалык турында хат йә аны кабул итүдән баш тарту турында мотивлаштырылган хат җибәрә.

3.3. Баш инвестицион-төзелеш идарәсеннән Мөлкәтне кабул итү-тапшыру актлары проектларын карап тикшерү нәтиҗәләре буенча дәүләт учреждениеләре, дәүләт унитар предприятиеләре электрон адреска аларны алган көннән 10 эш көне эчендә, имзаларын куеп, Мөлкәтне тапшыру-кабул итү актлары проектларын Баш инвестицион-төзелеш идарәсенә кертә. Баш инвестицион-төзелеш идарәсе Мөлкәтне кабул итү-тапшыру актларын дәүләт учреждениеләреннән, дәүләт унитар предприятиеләреннән алган көннән ике эш көне эчендә аларга кул куя. Дәүләт учреждениеләре, дәүләт унитар предприятиеләре Мөлкәтне кабул итү-тапшыру актларының имзаланган үз нөсхәләрен Баш инвестицион-төзелеш идарәсенә имзаланган Мөлкәтне кабул итү-тапшыру актларын керткән көннән 10 эш көне эчендә Баш инвестицион-төзелеш идарәсендә ала.

3.4. Баш инвестицион-төзелеш идарәсе җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан бу Тәртипнең 3.2 нче пунктында каралган Мөлкәтне кабул итүгә ризалык кергән көннән ике эш көне эчендә Министрлыкка мөрәҗәгать җибәрә.

3.5. Баш инвестицион-төзелеш идарәсенең мөрәҗәгатен Министрлыкта теркәгән көннән 15 эш көне эчендә Министрлыкның Мөлкәтне муниципаль милеккә яки оешмаларга файдалануга тапшыру турында боерык (алга таба – Боерык) кабул итүе Баш инвестицион-төзелеш идарәсенең бу Тәртипнең 3.4 нче пункты белән каралган мөрәҗәгатьләрен, шулай ук Баш инвестицион-төзелеш идарәсе тарафыннан җибәрелгән товар йөкнамәләре (спецификацияләр), кабул итү комиссиясе тарафыннан объектларны кабул итү актлары һәм Мөлкәтне кабул итүче оешмаларның вәкаләтле вәкилләре имзасын куйган башка кабул итү-тапшыру актлары күчермәләрен карап тикшерү нәтиҗәсе булып тора.

3.6. Боерыкны үтәү йөзеннән, Баш инвестицион-төзелеш идарәсе Боерык электрон документлар әйләнеше системасы аша Баш инвестицион-төзелеш идарәсенә кергән көннән ике эш көне эчендә Мөлкәтне кабул итү-тапшыру актлары проектларын әзерли һәм аны иярчен хат белән Министрлыкка кул куюга җибәрә.

3.7. Баш инвестицион-төзелеш идарәсенең иярчен хатын теркәгән көннән 15 эш көне эчендә Министрлыкның кабул итү-тапшыру актлары проектларын җирле үзидарә органнарына яки оешмаларга кул куюга җибәрүе яисә Баш инвестицион-төзелеш идарәсенең иярчен хатын теркәгән көннән өч эш көне эчендә кабул итү-тапшыру актлары проектларын, сәбәпләрне нигезләп, Баш инвестицион-төзелеш идарәсенә эшләп бетерү өчен кире кайтаруы Баш инвестицион-төзелеш идарәсе

тарафыннан кертелгән Мөлкәтне кабул итү-тапшыру актлары проектларын карап тикшерү нәтиҗәсе булып тора.

3.8. Министрлыктан алынган Мөлкәтне кабул итү-тапшыру актлары проектларына җирле үзидарә органнары яки оешмалар тарафыннан аларны алган көннән 10 эш көне эчендә имза куела һәм иярчен хат белән Министрлыкка җибәрелә.

3.9. Җирле үзидарә органнарының яки оешмаларның иярчен хатын теркәгән көннән 15 эш көне эчендә аларга Министрлык тарафыннан кул куелу яисә кабул итү-тапшыру актлары проектларының иярчен хатын теркәгән көннән 10 эш көне эчендә, сәбәпләрне нигезләп, аларны кире кайтару җирле үзидарә органнары яки оешмалар тарафыннан имзаланган Мөлкәтне кабул итү-тапшыру актлары проектларын карап тикшерү нәтиҗәсе булып тора.

3.10. Җирле үзидарә органнары яки оешмалар тарафыннан имзаланган Мөлкәтне кабул итү-тапшыру актлары проектлары, шулай ук Баш инвестицион-төзелеш идарәсе тарафыннан кертелгән казна мөлкәте составына Мөлкәтне кабул итү-тапшыру актлары проектлары Министрлык тарафыннан берьюлы теркәлә.

3.11. Баш инвестицион-төзелеш идарәсе, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар кабул итү-тапшыру актларының үз нөсхәләрен Министрлыкта кабул итү-тапшыру актларын рәсмиләштергән көннән 10 эш көне эчендә ала.